**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 14 февралендәге 373 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2015 елның 16 декабрендәге 4368 номерлы**
**«Шәһәр белән бәйле очрак барлыкка килгәндә Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыруга һәм алардан файдалануга килешүләр шартларын үтәүне тәэмин итү комиссиясе турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Шәһәр белән бәйле очрак барлыкка килгәндә Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыруга һәм алардан файдалануга килешүләр шартларын үтәүне тәэмин итү комиссиясе эшчәнлеген оптимальләштерү максатыннан карар бирәм:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 16 декабрендәге 4368 номерлы «Шәһәр белән бәйле очрак барлыкка килгәндә Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыруга һәм алардан файдалануга килешүләр шартларын үтәүне тәэмин итү комиссиясе турында»гы карарының (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 25 апрелендәге 1424 номерлы, 2017 елның 2 августындагы 2973 номерлы, 2022 елның 25 августындагы 2825 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 2699 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 2 номерлы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Шәһәр белән бәйле очрак барлыкка килгәндә Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыруга һәм алардан файдалануга килешүләр шартларын үтәүне тәэмин итү комиссиясе составыннан И.Р.Мөхәммәтшинны чыгарырга;

1.2. Шәһәр белән бәйле очрак барлыкка килгәндә Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыруга һәм алардан файдалануга килешүләр шартларын үтәүне тәэмин итү комиссиясе составына комиссия

әгъзасы буларак Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе башлыгының беренче урынбасары А.С.Рассихинны кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**